## АЙ ҖАНЫЙ, ВАЙ ҖАНЫЙ

*Татар халык җыры*

Җырла, җырла дип әйтәсез,
Сезгә нинди җыр кирәк?

Әй, сезгә нинди җыр кирәк?
Ай җаный, вай җаный,
Сезгә нинди җыр кирәк?
Сезнең өчен җыр җырларга
Сандугач тел кирәк.

Уфа — Казан юлларының
Баганалары чыршы,

Эх, баганалары чыршы.
Башларыңа моңнар төшсә,
Сез дә булырсыз җырчы.

Безнең юллар куе үлән,
Карап үтәргә кирәк,

Әй, карап үтәргә кирәк.
Җыр белмәгән, җыр сөймәгән
Безнең татарда сирәк.

Ай май үтә, май үтә,
Май үтә дә җәй җитә.

Эх, май үтә дә җәй җитә.
Май үткәнгә кайгырмагыз,
Безнең яшь гомер үтә.
Ай җаный, вай җаный,
Безнең яшь гомер үтә.